РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ ШИКШИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422053, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Шикши, ул. Школьная, 4
тел. (84362) 46-1-35

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЕКШЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422053, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Шекше авылы, Мәктәп урамы, 4
тел. (84362) 46-1-35

e-mail: Shik.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
03.04.2026

КАРАР
№ 14

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Советының җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында керемнәр турында белешмәләр урнаштыру мәсьәләләрен җайга салучы 26.12.2012 №32, 22.08.2017 №16 карарлары үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 28.12.2025 ел, №505-ФЗ Федераль законга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Шекше авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1.Үз көчләрен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Советының 26.12.2012 елның 32 номерлы «Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карары;

- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге Советының 22.08.2017 елның 16 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне бастырып чыгару өчен бирү Тәртибен раслау турында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Шекше авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче» карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shikshi адресы буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шекше авыл җирлеге Башлыгы Р.Р.Хәйртдинов